СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«_28_ »___май___ 2026 ел** **№ ___58___**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен раслау турында**

Гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын ныклап төзекләндерүне һәм төзекләндерүне финанс белән тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставына таянып, Арча район Советы карар **кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Арча район Советының “Арча муниципаль районының муниципаль юл фондын төзү турында” 2013 елның 12 октябрендәге 232 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында https://arsk.tatarstan.ru халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе А.Г.Хисаметдинов

Арча район Советының
“28” май 2026 ел
карарына
1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибе**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану кагыйдәләрен билгели.

1.2. Арча муниципаль районының муниципаль юл фонды (алга таба – юл фонды) – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетының (алга таба – район бюджеты) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү, шулай ук Арча муниципаль районы территориясендәге күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын ныклап төзекләндерү һәм төзекләндерү максатларында кулланылырга тиешле өлеше.

1.3. Юл фондының бюджет ассигнованиеләренең төп күрсәткечләре Арча район Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты турындагы карары белән юл фонды акчаларын куллануның тиешле юнәлешләре буенча билгеләнә.

## 2. ЮЛ ФОНДЫН ФОРМАЛАШТЫРУ

2.1. Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты турында карар белән район бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләменнән түбәндәгеләрдән ким булмаган күләмдә раслана:

1) Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына, турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизель һәм (яисә) карбюратор (инжектор) двигательләр өчен мотор майларына җирле бюджетка күчерелергә тиешле акцизлардан;

2) транспорт салымыннан район бюджеты керемнәреннән (әгәр Татарстан Республикасы законы белән транспорт салымыннан җирле бюджетларга чигерүләрнең бердәм нормативлары билгеләнгән булса);

3) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары белән китерелә торган зыянны каплау исәбенә түләүдән җирле бюджетлар керемнәреннән;

4) авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлардан җирле бюджетлар керемнәреннән;

5) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының муниципаль юл фондын төзүне күздә тотучы карары белән расланган җирле бюджетка башка кертемнәрдән.

## 3. ЮЛ ФОНДЫ АКЧАЛАРЫН КУЛЛАНУ

3.1. Юл фондының бюджет ассигнованиеләре түбәндәге юнәлешләр буенча кулланыла:

1) гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын карап тоту һәм төзекләндерү;

2) гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын проектлау, төзү (реконструкцияләү) һәм ныклап төзекләндерү;

3) күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын ныклап төзекләндерү һәм төзекләндерү;

4) җирле әһәмияттәге автомобиль юллары биләгән җир кишәрлекләренә карата хокукларны теркәү, инвентаризацияләү, паспортлаштыру, кадастр эшләрен башкару; гомуми файдаланудагы муниципаль әһәмияттәге автомобиль юлларына милек хокукларын рәсмиләштерү;

5) юллар төзүгә, төзекләндерүгә һәм карап тотуга бюджет кредитлары буенча бурычларны каплау;

6) җирле үзидарә органнарының юл эшчәнлеген тәэмин итү өлешендә законсыз гамәлләре (гамәл кылмавы) нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплау буенча РФ Суд актларын һәм җәмәгать килешүләрен үтәү.

3.2. Юл фондының бюджет ассигнованиеләре максатчан характерда була һәм әлеге бүлекнең 3.1 пунктында күрсәтелмәгән максатларга файдаланыла алмый.

3.3. Юл фонды акчаларыннан файдалануны контрольдә тоту юл фондының бюджет ассигнованиеләрен төп күрсәтүчеләргә, бюджет акчалары белән операцияләргә финанс контролен гамәлгә ашыручы органнарга йөкләнә.

3.4. Юл фондының агымдагы финанс елында файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре чираттагы финанс елында юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

3.5. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының башкарма органы ел саен муниципаль юл фонды акчаларыннан файдалану турында хисап төзергә һәм аны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына җибәрергә тиеш. Хисап җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап белән бер үк вакытта тапшырыла һәм басылып чыгарга тиеш.

3.6. Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләме:

- агымдагы финанс елында хисап финанс елында фактта кергән һәм әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә юл фондын формалаштырганда исәпкә алына торган район бюджеты керемнәренең фаразланган күләме арасындагы уңай аермага арттырылырга тиеш;

- агымдагы финанс елында хисап финанс елында фактта кергән һәм юл фондын формалаштырганда әлеге Тәртипнең 2.1 `пункты нигезендә исәпкә алына торган шәһәр бюджеты керемнәренең фаразланган күләме арасындагы

тискәре аермага киметелергә тиеш.